# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ДИМТАМАК АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР

№10 17 сентябрь 2019 ел

Татарстан Республикасы Ютазы
муниципаль районы Димтамак
авыл җирлегендә муниципаль хезмәт
турында Нигезләмәгә үзгәрешләр кертү
турында

Федераль һәм региональ законнарга туры китерү максатларында Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге советы **карар итте**:

1. Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлеге Советының 2017 елның 25 маендагы 7 номерлы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Димтамак авыл җирлегендә муниципаль хезмәт турындагы Нигезләмә» карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 8 статьяның 2 өлешендәге өченче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге статья максатларында муниципаль хезмәт стажын билгеләгәндә шулай ук дәүләт гражданлык хезмәте вазыйфаларындагы һәм аларга тиңләштерелгән хәрби хезмәт вазыйфаларындагы һәм федераль дәүләт хезмәтенең башка төрләре вазыйфаларындагы эш стажы исәпкә алына».

2) 12 статьяга түбәндәге эчтәлектәге 3нче өлешне өстәргә:

«3. Гражданин һәм муниципаль хезмәткәр, якын туганнары яисә кардәшләре муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы рәисе, муниципаль берәмлек башлыгы, җирле администрация башлыгы булганда, муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан суд һәм хокук саклау органнары җитәкчеләре (ата-анасы, хатыны, балалары, абыйсы-энесе, апасы-сеңлесе, хатыны-иренең ата-анасы, ир-белән хатынның балалары, балаларның ирләре һәм хатыннары) булганда, муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасары һәм аудиторы вазыйфаларына билгеләнә алмый.

3) 13 статьяда:

а) 1 өлешнең 3 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

3) эшмәкәрлек эшчәнлеге белән шәхсән яисә ышанычлы затлар аша шөгыльләнергә, коммерция оешмасы белән идарә итүдә яки коммерциячел булмаган оешма белән идарә итүдә катнашырга (сәяси партия белән идарә итүдә катнашудан тыш; җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән профсоюз органы белән идарә

итүдә, шул исәптән түләүсез нигездә башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органы белән идарә итүдә катнашудан тыш;  бүтән иҗтимагый оешма, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативлары, күчемсез милек хуҗалары ширкәтләренең съездында (конференциядә) яки гомуми җыелышында катнашудан тыш; күрсәтелгән коммерцияле булмаган оешмалар (сәяси партиядән һәм прфсоюз органыннан, шул исәптән җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында төзелгән башлангыч профсоюз оешмасының сайланулы органыннан тыш) белән идарә итүдә түләүсез катнашырга яисә аларның коллегиаль органнары составына яллаучы (эш бирүче) вәкиле рөхсәте белән керергә, ул муниципаль хокукый акт белән билгеләнгән тәртиптә алынган), муниципаль берәмлек тарафыннан муниципаль милектә булган оешманы яки идарә итүне гамәлгә куючы (устав капиталында катнашу өлешләре) вәкаләтләрен муниципаль берәмлек исеменнән гамәлгә кую тәртибен билгели торган муниципаль хокукый актлар нигезендә гамәлгә куючы (акционер) оешманың идарә һәм ревизия комиссиясе органнарында муниципаль берәмлек мәнфәгатьләрен түләүсез нигездә тәкъдим итүдән тыш; федераль законнарда каралган башка очракларда»;

б) түбәндәге эчтәлекле 2.1 өлеш өстәргә:

«2.1. Муниципаль хезмәткәр, җирле үзидарә органында, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратында җитәкче булганда, үз вазыйфасын биләгән чорда әлеге җирле үзидарә органының, муниципаль берәмлек сайлау комиссиясе аппаратының сайланулы профсоюз органында муниципаль хезмәткәрләр мәнфәгатьләрен яклый алмый".

4. 32 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

"32. Муниципаль хезмәт өчен шартнамә нигезендә кадрлар әзерләү

1. Муниципаль хезмәтнең югары квалификацияле кадрлар составын формалаштыру максатларында, җирле үзидарә органнары Россия Федерациясенең  мәгариф турында закончалыгы нигезендә һәм «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон нигезләмәләрен исәпкә алып, муниципаль хезмәт өчен гражданнар әзерләүне шартнамә нигезендә оештыра алалар.

2. Алга таба муниципаль хезмәт үтү йөкләмәсе белән шартнамә (алга таба - максатчан белем алу турында шартнамә) җирле үзидарә органы һәм граждан арасында төзелә һәм гражданның әлеге җирле үзидарә органында муниципаль хезмәт узу буенча укуларын тәмамлаганнан соң билгеләнгән срок эчендә йөкләмәсен күздә тота.

3. Максатчан укыту турында килешү төзү конкурс нигезендә башкарыла.

4. Конкурс җирле үзидарә органы тарафыннан игълан ителә һәм җирле үзидарә органында төзелә торган Конкурс комиссиясе тарафыннан үткәрелә.

5. Конкурс комиссиясе составына эшкә алучы (эш бирүче) вәкиле һәм (яки) аңа вәкаләтле муниципаль хезмәткәрләр (шул исәптән муниципаль хезмәт һәм кадрлар, юридик (хокукый) бүлекчәләрдән, ә мондый бүлекчәләр булмаган очракта) - муниципаль хезмәткәрләр, муниципаль хезмәт белән бәйле мәсьәләләр буенча бәйсез эксперт-белгечләр сыйфатында шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә чакырыла торган фәнни, мәгариф һәм (яки) башка оешмалар вәкилләре кертелә. Бәйсез экспертлар саны конкурс комиссиясе әгъзаларының гомуми санынннан кимендә дүрттән бер өлешне тәшкил итәргә тиеш.

6. Конкурс комиссиясе составы конкурс комиссиясе кабул иткән карарларга йогынты ясый алырлык мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау юлы белән формалаштырыла.

7. Конкурс комиссиясе конкурс рәисеннән, рәис урынбасарыннан, сәркатибеннән һәм комиссия әгъзаларыннан тора.

8. Максатчан укыту турында шартнамә төзүгә конкурс үткәрү турындагы мәгълүмат муниципаль хокукый актларны рәсми бастырып чыгару гамәлгә ашырыла торган массакүләм мәгълүмат чараларында бастырылып чыгарылырга һәм җирле үзидарә органының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә күрсәтелгән конкурсны үткәрү датасына бер айдан да соңга калмыйча урнаштырылырга тиеш.

9. Әлеге статьяның 8 пунктында каралган конкурсны үткәрү турындагы мәгълүматта күрсәтелә: уку тәмамланганнан соң гражданнар беләргә тиешле муниципаль хезмәт вазыйфалары төркемнәре; әлеге вазифаларга квалификация таләпләре; әлеге статьяның 11 пункты нигезендә конкурска тапшырыла торган документлар исемлеге, аларны кабул итү урыны һәм вакыты; күрсәтелгән документлар кабул ителә торган вакыт; конкурсны үткәрү датасы, урыны һәм тәртибе; максатчан укыту турында шартнамә төзүгә кандидатларны бәяләү һәм сайлап алу өчен файдаланыла торган конкурс процедуралары;  язма биремнең темасы (конкурс комиссиясе тарафыннан кулланыла торган конкурс процедураларының берсе язмача бирем булса), шулай ук башка мәгълүмат материаллары да булырга мөмкин.

10. Максатчан укыту турында шартнамә төзүгә конкурста катнашу хокукына Россия Федерациясе дәүләт телен белүче һәм көндезге уку формасы буенча беренче тапкыр Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетлары акчалары исәбеннән урта һөнәри яисә югары белем алучы гражданнар ия. Күрсәтелгән конкурста катнашучы граждан муниципаль хезмәткә керү вакытына, шулай ук әлеге статьяның 34 пунктында каралган

бөтен вакыт эчендә муниципаль хезмәт вазыйфаларын белү өчен «Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында» Федераль закон белән билгеләнгән таләпләргә туры килергә тиеш.

11. Конкурста катнашырга теләк белдергән граждан җирле үзидарә органына тапшыра:

1) шәхси гаризасын;

2) җирле үзидарә органына муниципаль хезмәткә керүче граждан тарафыннан җирле үзидарә органнарына тапшыру өчен фотосурәт теркәлгән федераль законнар нигезендә үз кулы белән тутырылган һәм имзаланган анкетаны;

3) паспортының күчермәсен (паспортның үзе конкурска килү белән шәхсән тапшырыла);

4) гражданинның хезмәт эшчәнлеген раслаучы хезмәт кенәгәсенең күчермәсен яисә башка документларны (элек хезмәт эшчәнлеге башкарылмаган очраклардан тыш);

5) "Россия Федерациясендә муниципаль хезмәт турында" Федераль закон нигезендә гражданның муниципаль хезмәткә керүгә һәм аны узуга комачаулаучы авыруның булмавы турында медицина оешмасы бәяләмәсе;

6) граждан беренче тапкыр Россия Федерациясе бюджет системасы бюджеты акчалары исәбеннән көндезге уку формасы буенча урта һөнәри яисә югары белем алуын, шулай ук үзе үзләштерә торган белем бирү программасы турында (һөнәрнең исемен, белгечлеге яки әзерлек юнәлешен күрсәтеп), гражданның уку планы нигезендә арадаш аттестацияләрне узу нәтиҗәләре турында, аның уставында һәм мәгариф оешмасының эчке тәртип кагыйдәләре белән каралган вазыйфаларны үтәү турында мәгълүматны үз эченә алган мәгариф оешмасы белешмәсен;

7) язмача биремне (конкурс комиссиясе тарафыннан кулланыла торган конкурс процедураларының берсе язмача бирем булса).

12. Җирле үзидарә органы җитәкчесе карары буенча әлеге статьяның 11 пункты нигезендә граждан тарафыннан тапшырылган документларга кертелгән персональ мәгълүматларның һәм башка белешмәләрнең дөреслеген һәм тулылыгын тикшерү гамәлгә ашырыла.

13. Дәгъва итүчеләрне бәяләү һәм сайлап алу үткәрелә торган конкурс комиссиясе утырышы әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән документларны кабул итү тәмамланган көннән соң 14 календарь көннән дә соңга калмыйча уздырыла. Конкурс комиссиясе утырышының урыны, датасы һәм вакыты турында конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан мондый утырыш үткәрелгән көнгә кадәр өч эш көненнән дә соңга калмыйча хәбәр

ителә. Конкурс комиссиясе утырышын конкурс комиссиясе рәисе үткәрә, ә ул булмаган очракта - конкурс комиссиясе рәисе урынбасары.

14. Конкурс комиссиясе утырышы, әгәр анда аның әгъзаларының гомуми санынннан кимендә өчтән икесе катнашса, тулы хокуклы була дип санала.

15. Конкурс комиссиясе карарлары ачык тавыш бирү юлы белән конкурс комиссиясе утырышында катнашучыларның күпчелек тавышы белән кабул ителә. Тавышларның тигезлеге очрагында , рәислек итүче конкурс комиссиясе утырышында тавыш биргән карар кабул ителгән дип санала.

16. Конкурс комиссиясе дәгъвачыларны әлеге статьяның 11 пунктындагы 1 - 6 пунктчаларында күрсәтелгән документлар, шулай ук конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча бәяли. Җирле үзидарә органы карары буенча конкурс процедуралары индивидуаль әңгәмә, тест һәм (яки) язмача биремне күздә тота.

17. Шәхси әңгәмә булачак һөнәри хезмәт эшчәнлеге өлкәсенә кагылышлы тема буенча дәгъвачы белән ирекле әңгәмә формасында үткәрелә, аның барышында претендент, теоретик белемнәрне һәм претендентның шәхси сыйфатларын бәяләү максатларында, конкурс комиссиясе әгъзаларының сорауларына җавап бирә.

18. Дәгъвачының теоретик белемнәрен һәм шәхси сыйфатларын бәяләү түбәндәге критерийлар буенча башкарыла:

1) теоретик белем дәрәҗәсе;

2) җавапның логик төзелеше;

3) грамоталылык һәм сөйләм культурасы;

4) дәгъвачының мәгариф оешмасында өлгереш дәрәҗәсе, фәнни мәкаләләр булу, фәнни конференцияләрдә, олимпиадаларда һәм мәгариф оешмалары үткәрә торган башка чараларда катнашуы;

5) һөнәри мотивациясе булу;

6) җирле үзидарә органнарында практика узу.

19. Шәхси әңгәмә нәтиҗәләре конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

1) Әгәр претендент эзлекле рәвештә, теманың эчтәлеген тулысынча ачса, өч балл;

2) әгәр претендент эзлекле рәвештә, теманың эчтәлеген тулысынча ачса , әмма төгәлсезлеккә һәм зур булмаган хаталарга юл куйса - ике балл;

3) әгәр претендент эзлекле булса , әмма теманың эчтәлеген тулысынча ачмаса, төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә - бер балл;

4) әгәр претендент теманың эчтәлеген ачмаса, шактый төгәлсезлекләр һәм хаталар җибәрсә - ноль балл.

20. Шәхси әңгәмә нәтиҗәләре буенча барлык конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан претендентка бирелгән баллар бергә кушыла.

21. Претендентларга тест үткәрү җирле үзидарә органы тарафыннан төзелә торган теоретик мәсьәләләр исемлеге нигезендә, Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен белү, шулай ук, максатчан укыту турындагы килешү нигезендә, гражданин муниципаль хезмәт үтәргә тиеш була җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне белү буенча үткәрелә.

22. Тест нәтиҗәләрен бәяләү дәгъвачының тест сорауларына бирелгән дөрес җавапларыннан чыгып, конкурс комиссиясе тарафыннан башкарыла.

23. Тест нәтиҗәләре буенча конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан дәгъва итүчеләргә куела:

1) тест сорауларының 86-100 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, биш балл;

2) тест сорауларының 70-85 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, дүрт балл;

3) тест сорауларының 51-69 процентына дөрес җаваплар бирелгән очракта, өч балл;

4) әгәр тест сорауларының 35-50 процентына дөрес җаваплар бирелсә, ике балл;

5) әгәр тест сорауларының 20-34 процентына дөрес җаваплар бирелсә, бер балл;

6) әгәр тест сорауларының  дөрес җаваплары  20 проценттан ким булса, ноль балл.

24. Язма бирем конкурс комиссиясе тарафыннан билгеләнгән һәм конкурсны үткәрү турында мәгълүматта күрсәтелгән тема буенча дәгъвачы тарафыннан басма рәвештә әзерләнә.

25. Язма биремнең темасы дәгъва кылучы тарафыннан Россия Федерациясе Конституциясе, Татарстан Республикасы Конституциясе, җирле үзидарә, муниципаль хезмәт, коррупциягә каршы тору өлкәсендә Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнары нигезләмәләрен белү, шулай ук җирле үзидарә органы эшчәнлеге өлкәсенә караган мәсьәләләрне белү буенча белем алуны ачыклау өчен сайлап алына.

26. Язма биремне бәяләү критерийлары - бирелгән теманы тулысынча ачу, язма сөйләм культурасы.

27. Язмача бирем конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бәяләнә:

1) өч баллга, әгәр претендент эзлекле рәвештә, язма бирем темасы эчтәлеген тулысынча ачса;

2) ике баллга, әгәр дәгъва кылучы эзлекле рәвештә язма биремнең эчтәлеген тулысынча ачса, әмма төгәлсезлекләргә һәм әһәмиятсез хаталарга юл куйса;

3) бер баллга, әгәр дә претендент эзлекле булса, әмма язма биремнең эчтәлеген тулысынча ачмаса, хаталарга һәм төгәлсезлекләргә юл куйса;

4) ноль баллга, әгәр дәгъва кылучы язма биремнәр темасы эчтәлеген бөтенләй ачмаса.

28. Язма биремне бәяләү нәтиҗәләре буенча претендентка бирелгән баллар конкурс комиссиясе әгъзалары тарафыннан бергә кушыла.

29. Конкурста җиңүче дип конкурс процедуралары нәтиҗәләре буенча иң күп балл җыйган дәгъва кылучы санала.

30. Конкурс комиссиясенең тавыш бирү нәтиҗәләре беркетмә белән рәсмиләштерелә, аңа конкурс комиссиясе утырышында рәислек итүче һәм конкурс комиссиясе секретаре тарафыннан имза салына.

31. Конкурс комиссиясенең җиңүчене билгеләү турындагы карары җирле үзидарә органы тарафыннан конкурста җиңгән претендент белән максатчан укыту турында шартнамә төзү өчен нигез булып тора.

32. Конкурста катнашкан гражданнарга аның нәтиҗәләре турында конкурс тәмамланганнан соң бер ай эчендә язма рәвештә хәбәр ителә.

33. Конкурста катнашуга бәйле чыгымнар (конкурс үткәрү урынына бару һәм кире кайту, торак урынын наемга алу, яшәү, элемтә чаралары хезмәтеннән файдалану һ.б.) гражданнар үз акчалары хисабына гамәлгә ашырыла.

34. Максатчан укыту тәмамланганнан соң муниципаль хезмәтне мәҗбүри үтү срогы максатчан укыту турында килешү белән билгеләнә. Күрсәтелгән срок максатчан уку турындагы шартнамә нигезендә гражданга социаль ярдәм күрсәтү чараларын биш елдан да артмаган вакыт эчендә җирле үзидарә органы биргән вакыттан да ким була алмый.

35. Максатчан укыту турында шартнамә якларының йөкләмәләре һәм җаваплылыгы Россия Федерациясе законнары нигезендә максатчан укыту турында шартнамә белән билгеләнә.

36. Максатчан укыту турында шартнамә гражданин белән бер тапкыр төзелергә мөмкин.

37. Максатчан укыту турында килешүдә каралган чыгымнарны финанс белән тәэмин итү җирлек бюджеты акчалары исәбеннән гамәлгә ашырыла».

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча урнаштыру юлы

белән  һәм Ютазы муниципаль районының www.yutaza.tatar.ru рәсми сайтында Интернет мәгълүмати-телекоммуникацион челтәрендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыкканнан (халыкка игълан ителгәннән) соң үз көченә керә.

Димтамак авыл җирлеге Башлыгы И.А.Сәләмов